| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от** 25.10.2022 г. Казань **№** 744/2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнардан алынган мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибен раслау турында» 2018 елның 31 июлендәге 213 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын актуальләштерү максатларында
б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнардан алынган мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибен раслау турында» 2018 елның 31 июлендәге 213 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2021 елның 12 ноябрендәге 651/2021 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктта «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнардан алынган мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның беренче абзацындагы сүзләреннән соң «(җаваплы кеше вазыйфаларын башкаручы) күрсәтелгән бәяләмәне алганнан соң өч эш көне эчендә» сүзләре белән тулыландырырга;

4 пунктның икенче абзацындагы җөмләне «4 пунктның беренче абзацындагы күрсәтелгән вакытта» сүзләре белән тулыландырырга;

5 пунктның икенче абзацында «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев